| СОВЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.06.2020 Әгерҗе шәһәре № 48-1

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесен
билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 48 статьясы һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына Вәлиев Азат Рөстәм улын билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы урынбасарына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Вәлиев Азат Рөстәм улы белән контракт төзергә.
3. Әлеге карарны «Әгерҗе хәбәрләре» («Агрызские вести») район газетасында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Муниципаль район башлыгы урынбасары,
Совет Рәисе урынбасары Р.Т. НУРИСЛАМОВ